СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.11.2021 г. Заинск № 73

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 29 октябрендәге 129 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 декабрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәренең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе һәм ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясына, Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Советының 2013 елның 29 октябрендәге 129 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 24 статьясына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.1 пунктта «минималь – 400 (600) кв. м.» сүзләрен «минималь – 1000 кв. м» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.2 пунктта «минималь – 400 (600) кв. м.» сүзләрен «минималь – 1000 кв. м» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 2.3 пунктта «минималь – 200 (300) кв. м; максималь – 1000 кв. м.» сүзләрен «минималь – 1000 кв. м; максималь – 1500 кв. м.» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җир мәсьәләләре, экология һәм ТКХ буенча депутат комиссиясенә (Р.В. Әгъләмов) йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**